| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**29.04.2026** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№73** |

Зеленодольск муниципаль районы Советының ««Махсус хәрби операциягә ярдәм иткән өчен» медален гамәлгә кертү турында» 2025 елның 29 декабрендәге 53 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Гражданнарны һәм иҗтимагый оешмалар коллективларын махсус хәрби операциядә катнашучыларга күрсәткән ярдәмнәре өчен бүләкләү максатыннан һәм медальнең исемен үзгәртү белән бәйле, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының ««Махсус хәрби операциягә ярдәм иткән өчен» медален гамәлгә кертү турында» 2025 елның 29 декабрендәге 53 номерлы карарына (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар исеменә үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Фронтка ярдәм өчен» медален гамәлгә кертү турында.

1.2. карарның 1 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Фронтка ярдәм өчен» медален гамәлгә кертергә.

1.3. карарның 2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Фронтка ярдәм өчен» медале турындагы кушытада бирелгән нигезләмәне расларга.

2. нигезләмәнең исеменә (карар кушымтасында) (алга таба – нигезләмә) үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фронтка ярдәм иткән өчен»медале турында нигезләмә.

2.1. нигезләмәнең 1.1 пунктындагы беренче абзацка үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. «Фронтка ярдәм өчен» медале (алга таба — Медаль) Зеленодольск муниципаль районы гражданнарын, иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) коллективларын һәм предприятиеләрен җәмәгатьчелек тарафыннан тану һәм бүләкләү формасы булып тора:».

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми (htpp:/pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында халыкка җиткерергә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы,**
**Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**